ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ОРФОГРАФИК СҮЗЛЕГЕ

44 000 сүз

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2024

УДК 811.512.145(038)
ББК 81.2Тат-4
Т 23

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
гыйльми советы карары нигезендә басыла*

Төзүчеләр:

*А. Ә. Тимерханов, Р. Т. Сәфәров, Ф. И. Таһирова, И. И. Сабитова,
Г. К. Һадиева, Х. Х. Кузьмина, Р. С. Нурмөхәммәтова,
Э. Х. Кадирова, Г. Р. Галиуллина*

Фәнни мөхәррир *Г. Р. Галиуллина*

Консультантлар: *К. Р. Галиуллин, Р. Т. Сәфәров*

Бәяләүчеләр:

филология фәннәре кандидаты *Э. И. Сафина,*
филология фәннәре кандидаты *О. Н. Галимова*

**Татар теленең орфографик сүзлеге** : якынча 44 000 сүз / төз.:
Т23 А. Ә. Тимерханов, Р. Т. Сәфәров, Ф. И. Таһирова һ. б.; фәнни мөх. Г. Р. Галиуллина. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2024. – 560 б.
ISBN 978-5-298-04739-5

«Татар теленең орфографик сүзлеге» якынча 44 000 сүзнең норматив язылышын тәкъдим итә. Сүзлек XXI гасырның беренче чирегенә формалашкан татар лексикасын чагылдыра. Белешмәлектә татар әдәби теле лексикасының төп фонды, шул исәптән соңгы чорда кулланышка кергән яңа сүзләр дә туплап бирелде.

Сүзлек киң катлау укучыга тәкъдим ителә.

УДК 81′374.823(038)
ББК 81.2Тат-4

ISBN 978-5-298-04739-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2024
© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024

# КЕРЕШ СҮЗ

Орфографик сүзлек ортологик сүзлекләр тибына керә, ягъни ул – әдәби тел нормаларын, беренче чиратта язылыш нормаларын ныгыту бурычын үти торган белешмәлек. Тел нормасы, бер яктан, һәр кулланучыга мәҗбүри, конвенциональ, кагыйдәләр һәм махсус норматив сүзлекләр белән кодификацияләнгән булса, икенче яктан, ул үзгәрүчән, хәрәкәтчән, еш кына вариатив. Орфографик норманың шактый катгый булуы белән бергә, вакыт үткән саен, орфографиягә дә үзгәрешләр кереп тора. Аларны һәм шулай ук фәндәге яңа карашларны, казанышларны чагылдыру өчен, әледән-әле яңа орфографик сүзлекләр төзеп бастыруга ихтыяҗ бар.

Татар лексикографиясе тарихында егермедән артык орфографик сүзлек булуы мәгълүм. Аларның иң әүвәлгеләре гарәп язуында, соңрак латин графикасында, яңараклары кириллицада төзелеп нәшер ителгән. Киң кулланышта йөргән мондый белешмәлекләр арасында А. Х. Нуриева, Ф. С. Фасеев, М. И. Мәхмүтовларның «Татар теленең орфографик сүзлеге» (1983), Ф. Ә. Ганиев белән И. И. Сабитоваларның «Татар теленең орфография сүзлеге» (2002), К. Р. Галиуллин белән Р. И. Раскуловаларның «Татар теленең орфографик сүзлеге» (2010, 2017) иң тулылары булып тора.

Бу белешмәлекләрдә бер-берсенә каршы килгән язылышлар да очрый. Сүзләр язылышындагы төрлелек телебездә шактый киң таралыш тапкан вариантлылык күренеше белән аңлатыла. Яңа орфографик сүзлекнең төп максатларыннан берсе – беренче чиратта хәзерге татар телендәге сүзләрнең язылышына төгәллек кертү һәм, соңгы чорда кулланышка кергән сүзләрне барлап, аларның орфографик норматив вариантын тәкъдим итү.

Булган сүзлекләргә әлеге эш барышында җитди анализ ясалды, татар теленең тарихи үсешенә бәйле үзенчәлекләр, алынма сүзләр бирелешендәге төп закончалыклар диахроник-синхроник яссылыкта системага салынды. Шулай ук төрле язылышта булган сүзләрнең сүзлекләрдә, вакытлы матбугат, матур әдәбият һәм фәнни хезмәтләрдә киң таралыш алган очраклары тикшерелеп, норматив буларак кабул ителде.

Лексикография фәнендә кабул ителгән кагыйдәгә нигезләнеп, махсус фәнни оешмада төзелгән, тел үсешенә бәйле үзенчәлекләрне һәм фәнни казанышларны исәпкә алып эшләнгән иң яңа белешмәлекләр алдарак нәшер ителгән сүзлекләрдән өстенрәк тора. Әлеге орфографик сүзлек, үзеннән алда кулланышта булган сүзлекләрдәге кимчелекләрне игътибар үзәгенә алып төзелгәнгә, соңгы нормаларны чагылдыра, һәм нәкъ шундагы язылыш гомуми кулланышка тәкъдим ителә.

Яңа «Татар теленең орфографик сүзлеге» XXI гасырның беренче чирегендә гамәлдә йөргән татар лексикасын чагылдыра. Норматив сүзлек буларак, ул киң катлау укучыга атап төзелә. Сүзлеккә, гомумкулланышта

булган актив лексикадан тыш, матур әдәбиятта, газета-журналларда һәм сөйләм телендә таралыш алган диалекталь һәм искергән сүзләр дә кертелде. Сүзлекнең шактый зур өлешен төрле фән өлкәләренә караган тармак терминологиясе алып тора.

Моңа кадәр чыккан белешмәлекләрдән аермалы буларак, яңа сүзлектә аерым сүзнең орфографиясенә генә түгел, сүзләр төрләнгәндә ялгана торган морфологик формаларның язылышына да зур игътибар бирелде: сүз формасының язылышында хәреф хатасы җибәрү ихтималы яки кушымчага бәйле рәвештә хәреф үзгәрешләре булган очраклар барысы да сүзлектә чагылдырылды. Мәсәлән, *китап, урындык* кебек сүзләрнең, тартым кушымчасы белән төрләнгәндә, соңгы тартыклары яңгыраулаша. Яки борын тартыкларына тәмамлана торган *урам, имән, аң* кебек сүзләрнең чыгыш килеше һәм күплек сан кушымчасы борын тартыгыннан башлана. Һәрбер сүз төркеменә хас морфологик кушымчаларның кыен очраклары сүз формалары рәтендә билгеләнеп барды. Аеруча фигыль формалары, бигрәк тә берничә варианты була алган инфинитив кушымчаларын унификацияләү, игътибар үзәгенә алынды. Сүзлекнең төзелеш принципларында һәрбер очрак аерым тәгаенләп бирелде.

Сүзлек Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре белән Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара бағланышлар институты тел белгечләре коллективы тарафыннан төзелде.

Сүзлекне төзү эше авторлар арасында түбәндәгечә бүленде: А. Ә. Тимерханов (А – Б хәрефләренә башлана торган сүзләр), Р. Т. Сәфәров (В – З), Ф. И. Таһирова (И – Коп), И. И. Сабитова (Кор – М), Г. К. Һадиева (Н – Р), Х. Х. Кузьмина (С – Тир), Р. С. Нурмөхәммәтова (Тис – Һ), Э. Х. Кадирова (Ц – Я). Сүзлекне редакцияләү, төзелеш принципларын эшләү һәм һәр өлешне яңа лексик берәмлекләр белән тулыландыру Г. Р. Галиуллина тарафыннан башкарылды.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12 йорт,
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты.
Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru

## СҮЗЛЕК ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Сүзләр алфавит тәртибендә бирелде.

2. Баш сүз (вокабула) калын хәрефләр белән, формалар гадәти хәрефләр белән бирелде.

3. Вокабулалар башлангыч формада бирелде, сүзнең үзгәрми торган өлешеннән соң вертикаль сызык куелды һәм үзгәрә торган өлеш китерелде; фигыльләрдә боерык фигыль формасы үзгәрми торган өлешкә тәңгәл килсә, ул форма урынына тильда куелды:

**апрел|ь**, -е(нә), -ьгә, -ьдән
**ае|к**, -грак
**кара|к**, -гы, -кка, -ктан
**кита|п**, -бы, -пка, -птан
**кия|ү**, -ве, -үгә, -үдән
**коен|у**, ~, -ды, -а, -ачак, -ырга, -уы
**кү|п**, -брәк

Әгәр үзгәреш булмаса, вертикаль сызык куелмады:

**аю**, -ы, -га, -дан
**бала**, -сы, -га, -дан
**зур**, -рак
**тиз**, -рәк

4. Сүзлеккә искергән, диалекталь сүзләр, терминнарның таралыш тапкан төрләре кертелде. Дәреслекләрдә, фәнни хезмәтләрдә очрый торган тарихи атамалар, терминнар рус теленнән алынган вариантта бирелде: *княжна, княгиня, сотня* һ. б.

5. Алынма сүзләрнең һәм аларның эквивалентлары актив кулланылган очракта, һәр икесе дә аерым сүзлек берәмлеге буларак теркәлде: *вклад, взнос, кертем* һ. б.

6. Борын тартыкларына (*м, н, ң*) тәмамланган сүзләрдә генә күплек сан кушымчасы да күрсәтелде:

**абориген**, -ы, -га, -нан, -нар
**аң**, -ы, -га, -нан, -нар
**алым**, -ы, -га, -нан, -нар
**биләм**, -е, -гә, -нән, -нәр

7. Соңгы иҗеккә төшмәгән очракларда басым билгесе куелды, басым соңгы иҗеккә төшкәндә билгеләнмәде.

Саф татар чыгышлы һәм үзләшеп беткән гарәп һәм фарсы алынмаларыннан ясалган парлы сүзләрнең басымы беренче компонентка төшә: *ата́-ана, ала́й-болай* һ. б.

И с к ә р м ә: рус теленнән кергән сүзләр парлашып килгән очракта, басым ике компонентка да куелды: *са́унд-продю́сер.* Парлы сүзләрнең *казыну́-*

*тикшеренү, таны́ш-тоныш, потенциа́л-регуля́тор* һ. б. ясалма төрләре, сирәк кулланылган очраклары сүзлектә урын алмады.

8. Парлы сүзләрнең кушымчасы, кагыйдә буларак, соңгы компонентка ялгана:

**ата́-ана**, -сы, -га, -дан
**вак-төя|к**, -ге, -ккә, -ктән

Башлангыч формада кулланылмый торган парлы сүзләрнең кайбер активрак кулланышта йөргәннәре генә бирелде. Шулай ук ике компоненты да төрләнгән очракларда тулы төрләнеше күрсәтелде:

**исә́п-сан,** исәбе-саны, исәбенә-санына, исәбеннән-саныннан

9. Сүзлеккә тезмә сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, тезмә терминнар кертелмәде. Бары тик төп сүз аерым кулланылмаган очракларда гына сүзтезмә аерым мәкалә буларак бирелде: *ва́з (~ кичү), игә-чөйгә (~ килү), гадәттән (~ тыш).*

10. Омонимнар аерым сүзлек мәкаләсе итеп бирелде һәм юл өсте гарәп цифрлары белән күрсәтелде, һәр омонимның кайсы сүз төркеменә каравы билгеләнде:

**яз|у**[1] *фг.*, ~, -ды, -а, -ачак, -арга, -уы
**язу**[2] *ис.*, -ы, -га, -дан

Әгәр теге яки бу сүзнең омонимнары күп булып, алар төрләнмәсә, бары тик киң таралган бер генә сүз төркеме күрсәтелде, мәсәлән: **я** *ымл.*

11. Сүзлектә контекстуаль башка сүз төркеменә күчү очраклары бирелмәде, бары тик сүзләр тулысынча конверсияләнгән чакта гына төрләнешнең башка сүз төркеме үзенчәлекләрен алган очраклары күрсәтелде:

**сор|ау**[1] *фг.*, -а, -ады, -ый, -аячак, -арга, -авы
**сора|у**[2] *ис.*, -вы, -уга, -удан

12. Сүзләргә стилистик кушымчалар ялганган вариантлар кертелмәде, әлеге төр кушымчалар сүз ясау вазифасын башкарган очраклар гына күрсәтелде.

13. *-лы/-ле, -сыз/-сез* кушымчалары сүз бәйләү вазифасын башкарган берәмлекләр шулай ук сүзлектә урын алмады, әмма әлеге төр кушымчаларның язылышында авырлык тудырган очраклар һәм аларның терминнар составында кулланылган очраклары бирелде, мәсәлән: *тоемлы, тоемсыз, төенле, төпкелле, чирәмле, читәнле, штольнялы, штырьлы; пресс, прессыз, билгеле, билгесез, теркәгечле, теркәгечсез, кодификацияле, кобальтлы, каюлы, комлы, койрыклы* һ. б.

14. Полифункциональ кушымчалардан шулай ук *-дай/-дәй, -тай/-тәй, -дагы/-дәге* кушымчалы сүзләр рәвеш, бәйлек һәм бәйлек сүз булып киткән очракларда бирелде:

**агымдагы**
**әүвәлге́дәй**
**баштагы**
**бу́лма́стай**

15. *ь, и* һәм *й* хәрефләренә тәмамланган сүзләрнең тартым кушымчасы янына җәяләр эчендә, сүзләрнең нинди (калын яки нечкә) нигезле икәнен күрсәтү өчен, юнәлеш килеше кушымчасы да китерелде:

**абыста|й**, -е(на), -йга, -йдан
**автопромы́шленност|ь**, -е(на), -ька, -ьтан
**җә|й**, -е(нә), -йгә, -йдән
**ла́гер|ь**, -е(на), -ьга, -ьдан

16. Алынма сүзьясагыч берәмлекләр, алга таба ничек язылуына карап, түбәндәгечә бирелде, мәсәлән: *альфа-, бета-; аква… блок…* һ. б.

17. Сүз башка формаларда кулланылмаса, *башка формалары юк* тамгасы куелды.

## Исемнәр бирелеше

1. Исемнәр баш килештә, берлек санда бирелде. Берлек санда кулланылмаган кайбер терминнар баш сүз буларак күплек сан формасында тәкъдим ителде, мәсәлән: *әвернәчәчәклеләр, карабодайчалар, китсыманнар* һ. б.

2. Сүзлек мәкаләсендә исемнең 3 зат тартым формасы, юнәлеш һәм чыгыш килеше формалары китерелә. Бу формаларның ясалышын һәм язылышын исемнең кушымчаларны үзенә алган үзгәрә торган өлешләре күрсәтә:

**кара|к**, -гы, -кка, -ктан
**кита|п**, -бы, -пка, -птан

3. Сүзлектә контекстуаль исемләшү очраклары урын алмады.

## Фигыльләр бирелеше

1. Фигыльләр исем фигыль формасында бирелде, шул ук мәкаләдә боерык фигыль, билгеле үткән заман, хәзерге, киләчәк заман хикәя фигыль формалары, инфинитив формасы һәм исем фигыльнең 3 зат тартымлы төрләнеше күрсәтелде:

**а|ву**, -у, -уды, -ва, -вачак, -варга, -вуы
**бө|гү**, -к, -кте, -гә, -гәчәк, -гәргә, -гүе
**би|ю**, -е, -еде, -и, -еячәк, -ергә, -юе
**кайт|у**, ~, -ты, -а, -ачак, -ырга, -уы

2. *-ып/-еп, -мыйча/-мичә* хәл фигыль кушымчалары белән төрләнгән сүзләр, конверсияләнеп, рәвешкә күчкән һәм язуда кыенлык тудырган очракларда гына сүзлектә урын алды, мәсәлән: *комлап, стаканлап, шикләнмичә, ышанмыйча* һ. б.

3. Үткән заман сыйфат фигыль кушымчасы белән килгән сүзләрнең дә язуда кыенлык тудырган очраклары гына бирелде, мәсәлән: *уңган, чикләнгән, чикләнмәгән, чишенгән, чукынган, шиңгән, юләрләнгән* һ. б.

4. Төрләнештә *ы* сузыгы кергән очраклар түбәндәгечә бирелде:

**кур|ку**, -ык, -ыкты, -ка, -качак, -кырга, -куы
**кыр|ку**, -ык, -ыкты, -ка, -качак, -кырга, -куы

### Сыйфатлар бирелеше

1. Сыйфатларның төп формасыннан соң чагыштыру дәрәҗәсе күрсәтелде:

**зур**, -рак
**киң**, -рәк
**а|к**, -грак

2. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар аерым мәкалә итеп бирелде, мәсәлән: *а́п-ак, са́п-сары* һ. б.

3. Нисби сыйфатлар төрләнешсез бирелде, мәсәлән: *җәйге, сәяси* һ. б.

### Алмашлыклар бирелеше

Алмашлык төркемчәләре һәм алардан ясалган башка сүз төркемнәре аерым берәмлек буларак тәкъдим ителде.

### Саннар бирелеше

Сүзлектә 19 санына кадәр, дистә саннарының атамалары (унлыклар), *йөз, миллион, миллиард* саннары аерым бирелә.

### Рәвешләр бирелеше

Рәвешләрнең төп формасыннан соң чагыштыру дәрәҗәсе булса, күрсәткече бирелде:

**тиз**, -рәк
**кү|п**, -брәк

### Ияртемнәр, ымлыклар, кисәкчәләр, бәйлекләр, хәбәрлек сүзләр, модаль һәм бәйләгеч сүз төркемнәре бирелеше

Бу төр сүзләр башлангыч формада, төрләнешсез бирелде:

**шап**
**абау**
**генә**
**белән**

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*алм.*– алмашлык
*бәйл.*– бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*бот.* – ботаника
*бүл. саны* – бүлем саны
*җыю саны* – җыю саны
*ис.* – исем
*иярт.* – ияртем
*к.* – карагыз
*кер. сүз* – кереш сүз
*кис.* – кисәкчә
*лингв.* – лингвистика
*мәс.* – мәсәлән
*мед.* – медицина
*миф.* – мифологизм
*мод. сүз* – модаль сүз
*муз.* – музыка
*рәв.* – рәвеш
*сан* – сан
*спорт* – физкультура һәм спорт
*сф.* – сыйфат
*тәрт. саны* – тәртип саны
*терк.* – теркәгеч
*фг.* – фигыль
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хим.* – химия
*чаг.* – чагыштырыгыз
*ымл.* – ымлык
*энд. сүз* – эндәш сүз
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| А а | З з | П п | Ч ч |
| Ә ә | И и | Р р | Ш ш |
| Б б | Й й | С с | Щ щ |
| В в | К к | Т т | ъ |
| Г г | Л л | У у | Ы ы |
| Д д | М м | Ү ү | ь |
| Е е | Н н | Ф ф | Э э |
| Ё ё | ң | Хх | Ю ю |
| Ж ж | О о | Һ һ | Я я |
| Җ җ | Ө ө | Ц ц | |

## Эчтәлек

Кереш сүз . . . . . . . . . . 3
Сүзлек төзелеше . . . . . . . . . . 5
Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . 9
Татар алфавиты . . . . . . . . . . 9
Орфографик сүзлек . . . . . . . . . . 10

Справочное издание

ОРФОГРАФИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Казань. Татарское книжное издательство. 2024

На татарском языке

Белешмә басма

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ОРФОГРАФИК СҮЗЛЕГЕ

Мөхәррире *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. Н. Мусина*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, А. М. Закирова, А. А. Гарипова, Т. Н. Сәгъдуллина*

16 + Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436 – ФЗ

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20. 12. 2024.
Форматы 60×90 1/32. Шартлы басма табагы 35,0.
Тиражы 3000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: +7(843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: +7(843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 51. Тел.: +7(843) 225-76-55.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: +7(927) 671-05-00.

**Маркетинг бүлеге:**
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: +7(843) 519-45-35.

**Интернет-кибет:**
**http://tatkniga.ru**